**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“12” ноябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пунктың башка территорияләрен төзекләндерү (Таш-Чишмә торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт өчен түләү).

2) Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Таш Чишмә торак пункты урам юлларын ремонтлау һәм ябу (вак таш сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

4) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (су кудырту насосы сатып алу).

5) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (су җыю башнясын буяу (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-

адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.